ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2024 ел Баулы шәһәре № 160

2025 елга Баулы муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге күппрофильле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законының 99 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 1 бүлекнең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 нормерлы «Татарстан Республикасы туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары һәм Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2025 елга расларга:

Баулы муниципаль районы туристик-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм

балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга 0,75 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

2. Баулы муниципаль районы финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә финанслау;

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнарын гамәлдә булу чоры дәвамында, балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 7 ноябрендәге
160 номерлы карары белән
РАСЛАНГАННАР

2025 елга Баулы муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында
туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге күппрофильле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар, бер укучыга елына сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм алдагы уку елы |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 8 280 | 15333 | 18399 |
| | авыл җирлеге | 8680 | 16074 | 19289 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 8179 | 15145 | 18174 |
| | авыл җирлеге | 8 579 | 15887 | 19064 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 8583 | 15895 | 19074 |
| | авыл җирлеге | 8984 | 16636 | 19963 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Экологик-биологик | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |

______________________